КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 20 май г.Казань № б-940

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 24 июль, б-1339 нчы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы; 2015 ел, 12 ноябрь, 851 нче; 2015 ел, 27 ноябрь, 896 нчы карарлары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 5 ноябрь, б-2202 нче; 2014 ел, 8 июль, б-1304 нче; 2014 ел, 13 август, б-1599 нчы; 2014 ел, 6 октябрь, б-1980 нче; 2014 ел, 30 декабрь, б-2850 нче; 2015 ел, 2 апрель, б-537 нче; 2018 ел, 26 июнь, б-1595 нче; 2018 ел, 20 декабрь, б-3524 нче; 2020 ел, 21 май, б-994 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы чараларын тормышка ашыру буенча ярдәмче төркем составын (боерыкка теркәлә) расларга.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» проектын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәдә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.3 пункт өстәргә:

«1.3. Эшче төркемдә Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы чараларын тормышка ашыру буенча ярдәмче төркем (алга таба – Эшче төркемнең ярдәмче төркеме) төзелә.»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Эшче төркем функцияләре

3.1. Эшче төркемнең төп функцияләре:

Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» системасын «бер тәрәзә» принцибы буенча үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеген координацияләү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең ачык булуын тәэмин итүгә, иҗтимагый советлар системасын камилләштерүгә һәм гражданлык контролен гамәлгә ашыруга, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советлар эшчәнлеге стандартларын формалаштыруга юнәлдерелгән төп чараларны билгеләү турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү һәм әлеге чараларны тормышка ашыруны тикшерүдә тоту;

дәүләт хезмәте белән идарә итүнең заманча ысулларын кертү, кадрлар потенциалын һәм дәүләт хезмәте кадрлары белән идарә итү системасын камилләштерү өчен, шул исәптән дәүләт идарәсе ихтыяҗлары өчен кадрлар резервын формалаштыру максатларында, «Ачык Татарстан» системасы механизмнарыннан файдалану турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

коррупциягә каршы көрәш, конкуренцияне үстерү һәм эшмәкәрлек климатын яхшырту өлкәсендә «Ачык Татарстан» системасы механизмнарыннан файдалану турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

мәгълүмат бирү ягыннан ачык булу стандартларын гамәлгә кертү (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының оешмалар белән электрон хезмәттәшлеген оештыру һәм электрон төрдә кире элемтәне тәэмин итү өлешендә) мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән дәүләт хакимияте башкарма органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен билгеләү, гамәлгә кертү һәм аларга ирешү турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

Татарстан Республикасы дәүләт милкеннән файдалану нәтиҗәлелеген арттыру турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

Татарстан Республикасы бюджеты нәтиҗәлелеген арттыру турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте эшчәнлегенең, Татарстан Республикасы дәүләт программаларының төп юнәлешләрен формалаштыру турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

«Россия иҗтимагый инициативасы» интернет-ресурсыннан файдаланып, Россия Федерациясе гражданнары җибәргән иҗтимагый инициативаларны карап тикшерү.

3.2. Эшче төркемнең ярдәмче төркеменә караган төп функцияләр:

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне камилләштерү, аның сыйфатын яхшырту һәм һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү;

«Ачык Татарстан» системасы эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен (дәүләт хезмәтләре сыйфатын бәяләүне һәм әлеге күрсәткечләргә ирешү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләүне кертеп) карап тикшерү, раслау, гамәлгә кертү һәм мониторинглау;

«бер тәрәзә» принцибы буенча, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләре базасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итү чараларын башкаруны оештыру;

«бер тәрәзә» принцибы буенча, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләре базасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүгә бәйле чараларны башкарганда һәм мәсьәләләрне хәл иткәндә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеген оештыру;

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы чараларын тормышка ашыруга бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү, шул исәптән федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары эшчәнлегенең Татарстан Республикасындагы инвестиция климаты торышына йогынтысын бәяләү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру өчен кирәкле чараларны оештыруга һәм гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлеген (дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль өлкәсендә норматив хокукый актлар проектларын карап тикшерүне, контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген цифрлаштыру процессларын гамәлгә кертүне кертеп) координацияләү.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм алардан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм «Ачык Татарстан» проектын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составын яңа редакциядә (боерыкка теркәлә) бәян итәргә;

әлеге боерыкка Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы чараларын тормышка ашыру буенча ярдәмче төркем составын (боерыкка теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 24 июль, б-1339 нчы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 май, б-940 нчы
боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» проектын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры, ведомствоара эшче төркем рәисе |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры, ведомствоара эшче төркем рәистәше |
| Шахов Дмитрий Анатольевич | «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең ачык хөкүмәт эшчәнлеген координацияләү бүлеге башлыгы, ведомствоара эшче төркем секретаре (килешү буенча) |

Ведомствоара эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әхмәтханов Җәүдәт Йосыф улы | Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бакулина Лилия Тәлгать кызы | Казан шәһәр Думасы депутаты, югары һөнәри белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең юридик факультеты деканы (килешү буенча) |
| Батков Федор Сергеевич | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Батюшов Абдулхак Мостафа улы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |
| Вафин Эдуард Яфас улы | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гайнетдинова Лилия Әхәт кызы | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе урынбасары (килешү буенча) |
| Галиев Марат Һади улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Галәвов Рөстәм Әсфан улы | Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гатауллина Наталья Вячеславовна | Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гыйниятуллина Лилия Марс кызы | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Груничев Александр Станиславович | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гущин Иван Николаевич | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе |
| Дмитриев Виктор Петрович | Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Зарипова Нажия Җәфәр кызы | Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә караган анализ һәм контроль-рөхсәт бирү эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Зиатдинов Радик Рәгыйп улы | Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе башлыгы |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Костин Артем Петрович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Крайнов Сергей Аркадьевич | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы |
| Кудрявцева Алевтина Николаевна | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |

| | |
|---|---|
| Кудряшов Василий Александрович | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |
| Кузюров Равил Әфраим улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Лоханов Павел Николаевич | Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесе идарәчесе (килешү буенча) |
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |
| Мифтахова Алсу Мансур кызы | «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Мозаффарова Ленара Әкмалетдин кызы | «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Потатушина Елена Николаевна | Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгына караган Идел буе төбәкара территориаль идарәсенең Татарстан Республикасындагы бүлеге (инспекциясе) башлыгы (килешү буенча) |
| Разинов Борис Николаевич | Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Рамазанов Радик Вахит улы | Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге идарәсе башлыгы урынбасары – баш дәүләт инспекторы урынбасары (килешү буенча) |
| Редько Ольга Андреевна | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Розенталь Андрей Николаевич | Федераль монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Алмаз Эдуард улы | Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасындагы һәм Ульяновск өлкәсендәге Төбәкара территориаль идарәсенең җир фонды белән идарә итү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабурская Сария Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафиуллин Марат Әдип улы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сәхбиев Рушан Флюр улы | Россия Саклык банкының Идел-Нократ банкы рәисе урынбасары – «Россия Саклык банкы» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татарстан банкы» бүлеге идарәчесе (килешү буенча) |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры – Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән |

| | |
|---|---|
| | тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Халиков Тимур Рафаэль улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары –Тармакара кулланучылар советының җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хисаметдинов Алмаз Гаптрәүп улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы |
| Хохорин Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры |
| Шәйхетдинова Любовь Николаевна | Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча). |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 24 июль, б-1339 нчы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 май, б-940 нчы
боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм алардан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы чараларын тормышка ашыру буенча ярдәмче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры, ярдәмче төркем рәисе |
| Кондратова Наталья Владимировна | икътисад министры урынбасары, ярдәмче төркем секретаре |

Ярдәмче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әхмәтханов Җәүдәт Йосыф улы | Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Батков Федор Сергеевич | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе |

| | |
|---|---|
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Груничев Александр Станиславович | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Гущин Иван Николаевич | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Зиатдинов Радик Рәгыйп улы | Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе башлыгы |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кәримуллин Таһир Вәгыйз улы | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрының беренче урынбасары |
| Крайнов Сергей Аркадьевич | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы |
| Кудрявцева Алевтина Николаевна | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |

| | |
|---|---|
| Кудряшов Василий Александрович | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |
| Кузюров Равил Әфраим улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы |
| Редько Ольга Андреевна | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хисаметдинов Алмаз Гаптрәүп улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры. |